РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 27 мае Кукмара ш. № 121

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Төбәк өчьяклы комиссиясе турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 35 статьясындагы 5 өлеше һәм«Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» 2004 елның 26 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, шулай ук Кукмара муниципаль районы территориясендә Социаль партнерлык системасын камилләштерү һәм социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча нәтиҗәлелекне арттыру максатларында Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Кукмара муниципаль районында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы комиссия турында кушымта итеп бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы комиссиясе турында» Кукмара район Советының 2008 елның 25 декабрендәге 84 номерлы карары;
- «Кукмара муниципаль районында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өч яклы комиссия турында» Кукмара муниципаль районы Советының 2013 елның 14 июнендәге 27 номерлы карары.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев

Кукмара муниципаль район Советының 2022 елның 27 маендагы 121 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Төбәк социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчьяклы комиссиясе турында Нигезләмә

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча территориаль өчьяклы комиссиясе (алга таба – Комиссия) гамәлдәге законнар нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының территориаль һөнәр берлекләре һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләре, җирле үзидарә органнары (алга таба – Комиссия яклары) вәкилләренең үзара килешүе нигезендә төзелә.

1.2. Комиссия эшчәнлегенең хокукый нигезен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында " 2004 елның 26 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге Нигезләмә тәшкил итә.

**2. Комиссияне формалаштыру принциплары һәм тәртибе**

2.1. Комиссия Комиссия яклары вәкилләренең Комиссия эшчәнлегендә ирекле катнашу принциплары, якларның паритетлыгы һәм тигез хокуклылыгы, аларның вәкилләренең хокукый вәкаләтләре, Комиссия якларының мөстәкыйльлеге һәм бәйсезлеге принципларына нигезләнеп, Комиссиядә үз вәкилләренең персональ составын билгеләгәндә төзелә.

Территориаль һөнәр берлекләре һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләреКомиссия составына үз вәкилләрен җибәрергә хокуклы.

Комиссия яклары вәкилләре комиссия әгъзалары булып торалар. Комиссия әгъзалары саны комиссиянең Якларның һәрберсеннән тигез һәм 10 кешедән артмый.

Комиссиянең сан ягыннан һәм персональ составыТатарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

2.2. Территориаль һөнәр берлекләре һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләре вәкилләрен Комиссиядә раслау һәм алмаштыру әлеге берләшмәләрнең органнары карары белән гамәлгә ашырыла.

2.3. Җирле үзидарә органнары вәкилләрен раслау һәм алмаштыру тиешле җирле үзидарә органы карары белән башкарыла.

**3. Комиссиянең максатлары һәм бурычлары**

3.1. Комиссиянең төп максатлары:

- социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу һәм якларның социаль-икътисади мәнфәгатьләрен килештерү;

- социаль партнерлык системасын үстерү;

- коллектив хезмәт бәхәсләрен (конфликтларны) җайга салуга ярдәм итү.

3.2. Комиссиянең төп бурычлары:

- проект әзерләү һәм территориаль килешү төзү буенча коллектив сөйләшүләр алып бару;

- территориаль килешүне үтәү барышында барлыкка килгән Комиссия яклары инициативасы буенча мәсьәләләрне карау;

- территориаль дәрәҗәдә социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен шартнамәчел җайга салуга ярдәм итү;

- социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре, хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү, социаль тәэмин итү өлкәсендә территориаль программалар проектларын эшләү белән бәйле мәсьәләләр буенча консультацияләр үткәрү;

- территориаль килешү үтәлешенең барышын тикшереп тору, аны үтәү барышында барлыкка килгән фикер каршылыкларын хәл итү, шулай ук килешүгә ирешмәгән мәсьәләләрне җайга салу.

## 4. Комиссиянең хокуклары

4.1. Комиссия хокуклы:

- территориаль килешүне эшләү, тормышка ашыру һәм Комиссия карарларын үтәгәндә Комиссия якларының мәнфәгатьләрен килештерергә;

- күмәк сөйләшүләр һәм территориаль килешү проектын әзерләү барышында Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Республика өчьяклы комиссиясе, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча тармак комиссияләре, социаль партнерлыкның башка органнары белән үзара хезмәттәшлекне тормышка ашырырга;

- үз карарлары үтәлешен контрольдә тотарга;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының социаль-икътисадый хәле турында, территориаль килешүне үтәүнең барышы һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында төзелә торган тармак килешүләре буенча Комиссия утырышында карала торган фикер каршылыкларын җайга салу мәсьәләләрен карау өчен кирәкле мәгълүмат алырга;

- үз эшчәнлегендә катнашу өчен Комиссия әгъзалары булмаган башка оешмалар вәкилләрен чакырырга, экспертларны, галимнәрне һәм белгечләрне җәлеп итеп, эшче төркемнәр оештырырга;

- закон нигезендә территориаль килешү проектын әзерләү һәм төзү тәртибен, территориаль килешү төзүдә катнашмаган эш бирүчеләрне кушу тәртибен законнар нигезендә билгеләргә;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының икътисади һәм социаль үсеше, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында төзелә торган тармак килешүләрен төзегәндә барлыкка килгән каршылыкларны җайга салумәсьәләләре буенча Комиссия якларының эшчәнлеген координацияләргә;

- социаль-хезмәт һәм алар белән бәйле икътисади мөнәсәбәтләрне җайга салу мәсьәләләре буенча һөнәр берлекләре вәкилләре һәм эш бирүчеләр катнашында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары үткәргән утырышларда карау өчен тәкъдимнәр кертергә;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары үткәрә торган утырышларда катнашу өчен, шулай ук әлеге органнар тарафыннан төзелгән комиссияләр эшендә катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә;

- Комиссия компетенциясенә керә торган, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнары, территориаль һөнәр берлекләре һәм аларның берләшмәләре, Комиссиядә тәкъдим ителгән эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләре тарафыннан карау өчен мәҗбүри булган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итәргә;

- социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив-хокукый актларын эшләүдә катнашырга;

4.2. Комиссия Комиссия регламентын эшли һәм раслый.

## 5. Комиссия координаторы

5.1. Комиссия координаторы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Комиссия якларының тәкъдимнәрен исәпкә алып билгеләнә. Координатор Комиссия әгъзасы булмый.

5.2. Комиссия координаторы:

- якларның координаторлары белән берлектә Комиссия эшчәнлеген оештыра, утырышларда рәислек итә;

- эш планнарын һәм Комиссия карарларын имзалый;

- якларның позициясен килештерүдә, уртак карарлар эшләгәндә һәм аларны гамәлгә ашырганда килешүгә килергә ярдәм күрсәтә;

- Комиссия секретариаты эше белән җитәкчелек итә;

- Комиссия эшендә катнашу өчен, Комиссия әгъзалары булмаган территориаль һөнәр берлекләре һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләре һәм җирле үзидарә органнары вәкилләрен, шулай ук галимнәрне һәм белгечләрне, башка оешмалар вәкилләрен чакыра;

- территориаль һөнәр берлекләре, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләре һәм җирле үзидарә органнары белән килешенеп, әлеге берләшмәләр һәм органнар тарафыннан үткәрелә һәм социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу белән бәйле мәсьәләләр карала торган утырышларда катнашу өчен Комиссия әгъзаларын җибәрә;

- үз компетенциясе кысаларында Комиссия утырышлары арасында оператив карарлар кабул итүне таләп итә торган мәсьәләләр буенча якларның координаторлары белән консультацияләр үткәрә;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советына Комиссия эшчәнлеге турында хәбәр итә;

- социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрелә торган чаралар турында Комиссиягә хәбәр итә.

5.3. Комиссия координаторы якларның эшчәнлегенә тыкшынмый һәм тавыш бирүдә катнашмый.

**6. Комиссия эшчәнлеген оештыру һәм карарлар кабул итү тәртибе**

6.1. Комиссия үз эшчәнлеген яклар тарафыннан имзаланган һәм Комиссия координаторы тарафыннан расланган Комиссиянең алдагы елга якларның тәкъдимнәрен исәпкә алып төзелә торган эш планы (алга таба – Комиссиянең эш планы) нигезендә башкара.

Комиссия утырышлары Комиссиянең эш планы нигезендә үткәрелә.

Комиссия утырышлары арасында оператив карарлар кабул итүне таләп итә торган мәсьәләләр буенча Комиссия координаторы яклар вәкилләре белән консультацияләр үткәрә. Бу очракта чираттан тыш карау өчен сораулар биргән як ике атна дәвамында утырыш уздыру өчен материаллар әзерләүне тәэмин итә (кертелә торган мәсьәләләр буенча мәгълүмат, карар проекты һ.б.).

6.2. Комиссия утырышы, әгәр утырышта һәр як составының 2/3 се катнашса, хокуклы дип санала.

Утырышларда Комиссия тарафыннан карала торган барлык мәсьәләләр буенча карарлар һәр якны тәкъдим итүче Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия тарафыннан кабул ителгән карарлар һәр якка да үтәү өчен мәҗбүри.

Кабул ителгән карар белән килешмәгән Комиссия әгъзалары Комиссия утырышы беркетмәсенә аларның аерым фикерен кертүне таләп итәргә хокуклы.

6.3. Комиссия эшчәнлеген оештыру һәм финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6.4. Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү өчен, Комиссия тарафыннан раслана торган 3 кешедән торган секретариат төзелә. Секретариат эше белән Комиссия координаторы җитәкчелек итә.

6.5. Комиссия секретариаты:

- Комиссия утырышларында карау өчен материаллар әзерләүне тәэмин итә;

- Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан, территориаль һөнәр берлекләре оешмаларыннан һәм аларның берләшмәләреннән, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләреннән Комиссия утырышларында каралырга тиешле мәсьәләләр буенча мәгълүматны сорый;

- Комиссия карарларын Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, территориаль һөнәри берлек оешмаларына һәм аларның берләшмәләренә, эш бирүчеләрнең территориаль берләшмәләренә үтәү өчен җибәрә;

- эш башкару эшен башкара һәм Комиссия документлары белән эшне оештыра.

6.6. Комиссия утырышлары Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында уздырыла.